Scientific Chronicles of the Turkic World
Төрки дөнья фәнни хроникасы
Научная хроника тюркского мира

# LATEST EVENTS IN 2014

In the Year of Culture and in accordance with the program “Kazan – the cultural capital of the Turkic world in 2014”, the Republican Center of Traditional Culture with the assistance of the Ministry of Culture of the Republic of Tatarstan and the International Organization of Turkic Culture (TURKSOY) held the International Scientific and Practical Conference “Intangible Cultural Heritage of the Turkic Peoples as an Object of Conservation”. The conference was held in the Hotel “Bilyar Palace” (Kazan, Ostrovski Str., 61) on 17-18 July, 2014.

The conference was attended by researchers, university professors, heads of cultural centers and art establishments, representatives of Turkic-speaking countries (Turkey, Azerbaijan, and Kazakhstan) and of ten regions of the Russian Federation. The conference presented four sections: “Topical Issues of Safeguarding Intangible Cultural Heritage”, “Intangible Cultural Heritage of the Turkic peoples: the Conservation of Language Environment”, “Intangible Cultural Heritage of the Turkic Peoples: Identification, Conservation and Research”; “Ethnic History and Traditional Culture of the Turkic peoples”. Experts in various areas (dialectology, ethnography, cultural studies, jurisprudence, economy, folklore, etc.) shared their experiences of working with intangible cultural heritage in the territory of the Russian Federation and abroad. The participants discussed issues of the priority areas, the measures of state support and the conservation of intangible cultural heritage, and the principles of identifying and fixing the objects of intangible cultural heritage of the Turkic peoples. They also addressed the issues of systematization and study of traditional Turkic culture, as well as the conservation of language as a medium of intangible cultural heritage.

On 17July, the Ministry of Culture of the Republic of Tatarstan hosted a press conference briefing on the issues raised at the conference. The following dignitaries spoke at the conference: the Deputy Minister of Culture of Tatarstan Guzel Azatovna Nigmatullina, the Director General of the State Russian House of Folk Art Tamara Valentinovna Purtova, the Director of the National Centre for the Development of Traditional Culture Fanzilya Hakimovna Zavgarova, the Head of the Sector for the Conservation of Intangible Cultural Heritage at the Ministry of Culture and Tourism of the Republic of Azerbaijan Yashar Huseynli, the Director of the “Khoomei” (Kyzyl) Zoya Kyrgys, the Scientific Secretary of the Kazakh Scientific Research Institute of Culture, the Minister of Culture of the Republic of Kazakhstan Omarbaev Yrysbek Kurbanbekovich.

This conference was an ideal venue for obtaining professional information and effective communication with colleagues.

The scholars of the Department of Tatar Philology and Intercultural Communication named after G. Tukay at Kazan Federal University participated in one of the main events devoted to the development of perspectives of the Frat Institute in Turkey.

On 15 October 2014 two Universities in Turkey hosted several events. The participants from Istanbul University were the Deputy Director of the Eurasian Institute, expert on the Tatar and Baskir languages Ismat Binar, and professor of the Turkic Languages Department at the Literature Faculty, and his students. The participants from Marmara University were the Assistant to Rector Prof. Erol Uzvar, the Head of Turkology Institute Gulshan Seihan Alyshlyk, and other scholars. The Head of the Department of Tatar Philology and Intercultural Communication named after G.Tukay Prof. Alfiya Yusova spoke about the Institute and the Department, described its pedagogic and methodological activities, and outlined plans for the future. She also dealt with the issue of bilingualism in the Republic of Tatarstan and the opportunities both for the holders of master degrees and undergraduates offered by the exchange program of the Universities. G.Galiullina's report on the *Tatarica* journal, Z.Kirillova's presentation of the on-line school "Ana tele" attracted the attention of students and faculty.

Our university scholars participated in the 7$^{th}$ International Symposium "Turkish is the World Language," held on October, 16-18 at Frat University in Elazig, Turkey. About 180 Turkologists from Turkey and other countries took part in this symposium, among them were researchers from Istanbul, Ankara, Marmara, Frat, Aidyn, Ulug-Tau, Mugla, Ege and Osmangazi Universities as well as others from Russia, Kazakhstan, Kyrgyzstan, Turkmenistan, Azerbaijan, Macedonia, Kosovo, Egypt, Afghanistan, and China. At the plenary session, outstanding Turkish scientists Neuzat Yalchintash, Abdurakhman Guzel, Tunser Guulensou, Khamsa Zulficar, Dorsum Il Durum, and Ficret Turkmen gave their speeches. Over two days 167 reports were presented in 29 sections. Each report was noteworthy and aroused discussion. The researchers spoke on the past, present and future of the Turkic language. The largest delegation was from Russia – Kazan. Our scholars, F.Yu.Yusupov, F.Sh.Nurieva, A.Sh.Yusupova, G.R.Galiullina, F.S.Saifullina, T.Sh.Gyilazhev, E.Kh.Kadirova, Z.N.Kirillova, G.R.Shamsieva gave their reports on the Golden Horde, the Kazan khanate, dictionaries of the 19$^{th}$ century, Tatar-Turkic literature, cultural relations in the 20$^{th}$ century, different ethnographic groups of Tatars, and the current state of the Tatar language. For the first time, such rewards as "The Outstanding Scholar Who Devoted a Lifetime to the Turkish Language" and "The Leading Institution of the Turkish Language" were awarded. Ramazan Korkmaz was named the Outstanding Scholar and Yunus Emre Institute was announced as the Leading Institution of this year. Next year the Symposium "Turkish is the World Language" is planned be held in Canakkale University.

The Symposium made the decision to continue international communication and collaboration. The Journal *Tatarica* was named as a connection between Turkic peoples both in culture and science.

---

On November 19-21, 2014 the 3$^{rd}$ International Scientific and Practical Forum "Preservation and Development of Languages and Cultures" was held in Kazan at the Institute of Philology and Intercultural Communication, Kazan Federal University.

The event was timely due to the fact that the preservation and development of languages and cultures in the conditions of a changing world and globalization are two of the most important issues for modern society. To solve this issue it is necessary to conduct a scientifically-based and balanced language policy to create the common space of science and education.

Only comprehensive measures, a systemic approach and international and interregional cooperation will help to preserve the linguistic and cultural diversity of the world.

The forum was opened by the Rector of Kazan Federal University Ilshat Rafkatovich Gafurov. He noted that linguistic research has always occupied one of the leading places in the activities of Kazan University. In his speech, the Rector recalled the names of such prominent linguists as Baudouin de Courtenay, N.Krushevsky, V.Bogoroditsky, A.Kazimbek, and M.Kurbangaliev. 'Kazan University has always been a center both for science and education, for culture and enlightenment', said I.R.Gafurov. The rector also highly appreciated the current activity of the Institute of Philology and Intercultural Communication, citing the work of the Kazan International Linguistic Centre, the language centers, and projects under the state program "The preservation, study and development of the state languages of the Republic of Tatar-

stan and other languages in the Republic of Tatarstan for 2014-2020" aimed at raising the authority of the Russian and Tatar languages and their development in the social and cultural space.

At the opening ceremony, welcome speeches were also made by the Director of the Institute of Philology and Intercultural Communication Radif Zamaletdinov, the Head of the Department of International Cooperation and Support of Russian State Policy in the sphere of children and youth education at the Ministry of Education and Science of the Russian Federation Sargylana Matveevna Bryzgalova, the Chairman of the State Council of the Republic of Tatarstan on Culture, Science, Education and National Issues Razil Valiev and other Russian and foreign guests.

The forum hosted more than 500 participants: researchers, teaching employees, and heads of educational institutions, employees of federal, regional and municipal education authorities, scientific and other institutions connected with the theoretical and practical study of the issues related to the preservation and development of native languages and cultures, postgraduate students, undergraduates and students of higher and secondary vocational schools of the Republic of Tatarstan, Moscow, St. Petersburg, Yekaterinburg, Rostov-on-Don, Belgorod, Nizhniy Novgorod, Stavropol, Ufa, Yoshkar-Ola, Cheboksary, Saransk, and other Russian cities as well as many researchers from the CIS and foreign countries: Germany, Finland, Turkey, Latvia, Kazakhstan, Uzbekistan, etc.

A number of scientific and educational activities were held within the framework of the forum:

- The 5th International Scientific and Practical Conference "Preservation and development of native languages in a multinational state: problems and prospects";
- The 2nd International Scientific and Practical Conference "Art and art education in the context of cross-cultural interaction";
- International Scientific and Practical Conference "Russian-German crossroads: Language – education – culture";
- International Scientific and Practical Conference "Preservation of the artistic and historical environment of the modern city as a spiritual factor of culture";
- International Scientific and Practical Conference "Current aspects of applied comparative linguistics: Teaching a foreign language with native language support";
- All-Russian Scientific and Practical Conference "Network-based multilingual education of gifted children: problems and prospects";
- The 7th Republican Contest on the Tatar language for Russian-speaking students.

In total, the forum had 2 plenary sessions (opening and closing sessions), 19 conference sessions, 6 round tables and 4 master classes, which were attended by over 500 people.

The 3rd International Scientific and Practical Forum "Preservation and Development of Languages and Cultures" has become a major scientific and cultural event and has contributed to a fruitful exchange of information and research results between scientists from many regions of the Russian Federation, the CIS, and foreign countries. In the course of its work, participants discussed topical issues relating to the preservation and development of languages and cultures, as well as the study, dissemination, and best practices in this area. Research materials presented at the forum reflected the latest scientific achievements and advanced experience in the field of learning and teaching languages, music, dance and visual arts.

*The information was submitted by I.Yarmakeev, Doctor of Education, Professor of the Institute of Philology and Intercultural Communication, Kazan Federal University; E.Kadyrova, PhD in Philology, Associate Professor of the Institute of Philology and Intercultural Communication, Kazan Federal University, and L.Kh.Davletshina, PhD in Philology, Senior Researcher of the Center of Republican Centre for development of traditional culture.*

# 2014 НЧЕ ЕЛДА БУЛГАН ВАКЫЙГАЛАР

Мәдәният елы һәм «Казан – төрки дөньяның башкаласы 2014» программасы кысаларында Мәдәният министрлыгы һәм Төрки мәдәният халыкара оешмасы «ТЮРКСОЙ» ярдәмендә Республика традицион мәдәниятне үстерү үзәге «Саклау объекты буларак төрки халыкларның матди булмаган мәдәни мирасы» конференциясен үткәрде. Конференция 16-19 нчы июльдә Казанда «Биләр Палас» кунакханәсендә (Казан ш., Островский ур., 61нче йорт) узды.

Конференция эшендә фәнни үзәк галимнәре, югары уку йортлары укытучылары, мәдәни үзәк һәм иҗат йортлары җитәкчеләре, төрки дәүләтләрдән (Төркия, Әзербайҗан, Казахстан) һәм Россия Федерациясенең 10 регионыннан вәкилләр катнашты. Конференция эше дүрт секциядә алып барылды: «Матди булмаган мәдәни мирасны саклауның актуаль мәсьәләләре», «Төрки халыкларның матди булмаган мәдәни мирасы: тел мохитен саклау мәсьәләсе», «Төрки халыкларның матди булмаган мәдәни мирасы: ачыклау, саклау һәм өйрәнү», «Төрки халыкларның этник тарихы һәм традицион мәдәнияте». Төрле өлкә галимнәре (диалектологлар, этнографлар, культурологлар, хокук белгечләре, икътисадчылар, фольклорчылар һ.б.) Россия Федерациясе территориясендә һәм чит илләрдә матди булмаган мәдәни мирас белән эшләү тәҗрибәсе белән уртаклаштылар, һәм аны дәүләт күләмендә саклау мәсьәләсе хакында сүз алып барылды, матди булмаган мәдәни мирас объектларын туплау һәм фиксацияләү принциплары барланып, төрки халыкларның традицион мәдәниятен өйрәнү һәм системалаштыру проблемалары ачыкланды һәм, әлеге мирасның бер формасы буларак, тел мәсьәләләре турында фикер алышу булды.

17 нче июльдә ТР ның Мәдәният министрлыгында узган пресс-конференциядә Татарстан Республикасы мәдәният министры урынбасары Гүзәл Азатовна Нигъмәтуллина, Россия халык иҗаты йорты генераль директоры Пуртова Тамара Валентиновна, Республика традицион мәдәниятне үстерү үзәге директоры Фәнзилә Хәкимовна Җәүһәрова, Әзербайҗан Республикасының Мәдәният һәм туризм министрлыгының матди булмаган мәдәни мирасны саклау бүлеге мөдире Яшар Гусейнли, «Хоомей» халыкара фәнни үзәге директоры (Кызыл ш.) Зоя Кыргысовна Кыргыс, Казахстан Республикасы Мәдәният министрлыгының Казах фәнни-тикшеренү институты гыйльми секретаре Омарбаев Ырысбәк Курбанбәкович конференциядә күтәрелгән мәсьәләләр хакында сөйләделәр.

---

Казан федераль университетының Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты Г.Тукай исемендәге Татар филологиясе һәм мәдәниятара багланышлар бүлеге галимнәре Төркиядә институтның киләчәк үсеш перспективасы белән бәйле эшлекле һәм нәтиҗәле чараларда катнаштылар. 2014 елның 15 октябрендә Төркиянең Истанбул шәһәрендәге ике университетында очрашулар узды. Истанбул университетының Евразия институты директоры урынбасары, әдәбият факультеты төрки телләр бүлегенең татар һәм башкорт телләре белгече профессор Исмәт Бинәр җитәкчелегендә студентлар һәм Мәрмәрә университеты җитәкчелеге - университетның ректор ярдәмчесе профессор Эрол Өзвар, Тюркология институты мөдире профессор Гүлшән Сәйһан Алышык һәм башка галимнәре белән булган очрашуда Татар филологиясе һәм мәдәниятара багланышлар бүлеге мөдире профессор Ә.Ш.Юсупова институт һәм бүлек структурасы, гыйльми һәм педагогик-методик эшчәнлек юнәлешләре һәм киләчәк планнар белән таныштырды, Татарстан Республикасында татар теленең кулланылу өлкәләрен бәян итте, ике югары уку йорты арасында хезмәттәшлекне киңәйтү максатында студентлар һәм магистрлар алмашу мөмкинлекләре барлыгын ассызыклады. Профессор Г.Р.Галиуллинаның «TATARICA» журналы хакындагы җентекле мәгълүматы, доцент З.Н.Кириллованың «Ана теле» онлайн-мәктәбе турындагы чыгышлары укытучыларда һәм студентларда зур кызыксыну уятты.

Галимнәребез VII Халыкара «Дөнья теле – төрекчә» симпозиумында катнашты. Ул 2014 елның 16-18 октябрендә Төркиянең Элазыг шәһәрендәге Фрат университетында узды. Әлеге чарада Төркиядән һәм дөньяның күп кенә илләреннән барлыгы 180 тюрколог галим катнашты. Төркиянең Истанбул, Әнкара, Мәрмәрә, Фрат, Айдын, Олы Тау, Мугла, Эгей, Османгази һәм башка университетларыннан тыш, Россия, Казахстан, Кыргызстан, Төркмәнстан, Әзербайҗан, Албания, Македония, Косово, Мисыр, Әфганстан, Кытайдан дәрәҗәле галимнәр чакырылган иде. Пленар

утырышта Төркиянең Нәүзат Ялчынташ, Абдррахман Гүзәл, Түнсәр Гууленсоу, Хәмзә Зөлфикар, Дурсун Йылдырым, Фикрәт Төркмән кебек дәрәҗәле тюркологлары чыгыш ясады. Симпозиумда ике көн дәвамында 29 секциядә барлыгы 167 доклад тыңланды. Һәр доклад зур кызыксыну һәм игътибар белән кабул ителгән утырышларда галимнәр төрки телләрнең тарихы, бүгенгесе, киләчәге турында сөйләштеләр, фикер алыштылар. Чит илләрдән килгән делегацияләр арасында иң зурысы Россиядән – Казаннан иде. Галимнәребез Ф.Ю.Юсупов, Ф.Ш.Нуриева, Ә.Ш.Юсупова, Г.Р.Галиуллина, Ф.С.Сәйфуллина, Т.Ш.Гыйлаҗев, Э.Х.Кадыйрова, З.Н.Кириллова, Г.Р.Шәмсиевaларның Алтын Урда, Казан ханлыгы чоры, XIX йөз сүзлекләре, XX йөз башында татар-төрек әдәби һәм мәдәни бәйләнешләре, татар халкының аерым этнографик группалары, татар теленең бүгенге торышы турындагы чыгышлары конференциядә катнашучыларда зур кызыксыну уятты. Җиде ел дәвамында ел саен үткәрелеп килгән әлеге чарада быел беренче тапкыр «Төрек теленә хезмәт итүдә алдынгы галим», «Төрек теленә хезмәт итүдә алдынгы оешма» премияләре бирелде. Бу елның фән кешесе буларак, доктор Рамазан Коркмаз билгеләнде, алдынгы оешма исемен Юныс Әмре институты алды. Халыкара «Дөнья теле – төрекчә» симпозиумын алдагы елда үткәрү уку йорты билгеләнеп, Фрат университетыннан эстафета Чанаккале университетына тапшырылды.

Симпозиум хуҗалары һәм кунаклар арасында булган әңгәмәләр барышында үзара хезмәттәшлек итү мәсьәләләре дә алга куелды, шулай ук киләчәктә төрки халыклар арасында мәдәни һәм фәнни дуслык җепләрен ныгытуга юл ачачак «TATARICA» журналы тәкъдим ителде.

---

19-21 нче ноябрь көннәрендә Казан федераль университетының Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында «Телләрне һәм мәдәниятләрне саклау һәм үстерү» дип аталган III Халыкара фәнни-гамәли форум булып узды.

Чараны үткәрүнең актуальлеге глобальләштерү һәм тиз үзгәрүчән дөнья шартларында телләрне һәм мәдәниятләрне саклау һәм үстерү мәсьәләсе хәзерге җәмгыятьтә иң төп мәсьәләрнең берсе булуы белән билгеләнә. Аны уңышлы хәл итү өчен, фәнни яктан нигезле тел сәясәте үткәрү һәм бердәм фәнни-мәгариф тирәлеген формалаштыру мөһим. Комплекслы чаралар, системалы һәм эшлекле якын килеп, халыкара, төбәкара хезмәттәшлек итү генә дөньяның тел һәм мәдәни төрлелеген сакларга ярдәм итә.

Форумны Казан федераль университеты ректоры Илшат Рәфкать улы Гафуров ачты. Ул Казан университеты эшчәнлегендә лингвистика әйдәп баручы юнәлешләрнең берсе булуын күрсәтеп, Бодуэн де Куртенэ, Н.Крушевский, В.Богородицкий, А.Казембек, М.Корбангалиев кебек танылган тел галимнәрен искә алып үтте. Ректор: «Казан университеты фән һәм белем бирүдән тыш, мәдәният һәм мәгърифәт тарату үзәге дә булып тора», – дип ассызыклады. Гафуров, Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты эшчәнлеген югары бәяләп, Казан халыкара лингвистик һәм татар теленә өйрәтү «Ана теле» онлайн-мәктәбе үзәкләренең эшчәнлеген киңәйтүгә, шулай ук рус һәм татар телләренең кулланылыш имиджын һәм дәрәҗәсен үстерүгә юнәлтелгән «2014 – 2020 нче елларда Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү дәүләт программасы» кысаларында башкарылган проектларны билгеләп узды.

Тантаналы ачылышта Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты директоры Рәдиф Җамалетдинов, Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының Балалар һәм яшьләрне тәрбияләү өлкәсендә дәүләт сәясәте департаментының халыкара хезмәттәшлек һәм рус теленә ярдәм итү бүлеге башлыгы Саргылана Матвеевна Брызгалова, Татарстан Дәүләт Советының Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Разил Валиев, шулай ук Россия һәм чит илләрдән килгән башка кунаклар чыгыш ясады.

Форум эшендә 500 дән артык галим, педагогик хезмәткәр, белем бирү учреждениеләре җитәкчеләре, мәгариф идарәсенең федераль, төбәк һәм муниципаль оешмалары, шулай ук фәнни, туган телләрне һәм мәдәниятләрне саклау һәм үстерү мәсьәләләрен назәри һәм гамәли яктан өйрәнгән башка оешма хезмәткәрләре, Татарстан Республикасы һәм Мәскәү, Санкт-Петербург, Екатеринбург, Ростов-на-Дону, Белгород, Түбән Новгород, Ставрополь, Уфа, Йошкар-Ола, Чебоксар, Саранск кебек Россия шәһәрләренең югары һәм урта һөнәри уку йортларыннан аспирантлар, магистрлар һәм студентлар, шулай ук ерак һәм якын чит илләр: Германия, Финляндия, Төркия, Латвия, Казахстан, Үзбәкстаннан галимнәр катнашты.

Форум кысаларында күптөрле фәнни һәм мәгариф чаралары үткәрелде:

- «Күпмилләтле дәүләт шартларында туган телләрне һәм әдәбиятларны саклау һәм үстерү: проблемалар һәм перспективалар» V Халыкара фәнни-гамәли конференциясе;
- «Мәдәниятара бәйләнеш контекстында сәнгать һәм аны укыту» II Халыкара фәнни-гамәли конференциясе;
- «Россия-Германия багланышлары: тел – мәгариф – мәдәният» Халыкара фәнни-гамәли конференциясе;
- «Мәдәниятнең рухи факторы буларак заманча шәһәрнең мәдәни-тарихи мохитен саклау» Халыкара фәнни-гамәли конференциясе;
- «Чагыштырма лингвистиканың гамәли аспектлары: туган тел нигезендә чит телгә өйрәтү» Халыкара фәнни-гамәли конференциясе;
- «Сәләтле балаларны полилингваль челтәр аша укыту: проблемалар һәм перспективалар» Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясе;
- Рус телле студентлар өчен татар теленнән VII Республика олимпиадасы.

Форум вакытында ике пленар утырыш (төп һәм йомгаклау), 19 секция утырышы, 6 түгәрәк өстәл, 4 мастер-класс эшләде.

«Телләрне һәм мәдәниятләрне саклау һәм үстерү» III Халыкара фәнни-гамәли форумы зур фәнни һәм мәдәни вакыйга буларак, Россия Федерациясе һәм ерак һәм якын чит ил төбәкләре галимнәре арасында үзара мәгълүмат һәм фәнни тикшеренү нәтиҗәләре алмашуга ярдәм итте.

Эш барышында телләрне һәм мәдәниятләрне саклауга, бу юнәлештә алдынгы тәҗрибәне өйрәнү, уртаклашу һәм гомумиләштерүгә бәйле әһәмиятле мәсьәләләр каралды. Форумда тәкъдим ителгән фәнни материалларда телләрне, музыка, хореография һәм сынлы сәнгатьне өйрәнү һәм укыту өлкәсендә яңа фәнни казанышлар, алдынгы педагогик тәҗрибә яктыртылды.

*Материалларны педагогика фәннәре докторы, Казан федераль университетының Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты профессоры И.Э.Ярмәкәев, Казан федераль университетының Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты доценты, филология фәннәре кандидаты Э.Х.Кадыйрова, Татарстан Республикасы традицион мәдәниятне үстерү үзәгенең өлкән фәнни хезмәткәре, филология фәннәре кандидаты Л.Х.Дәүләтшина әзерләде.*

# СОБЫТИЯ, КОТОРЫЕ ПРОИЗОШЛИ В 2014 ГОДУ

В рамках Года культуры и плана основных мероприятий программы «Казань – культурная столица тюркского мира 2014 года» Республиканским центром развития традиционной культуры при содействии Министерства культуры Республики Татарстан и Международной организации тюркской культуры (ТЮРКСОЙ) 16-19 июля 2014 года проведена Международная научно-практическая конференция «Нематериальное культурное наследие тюркских народов как объект сохранения». Конференция проходила 17-18 июля 2014 года в гостиничном комплексе «Биляр Палас» (г. Казань, ул. Островского, 61).

В работе конференции приняли участие ученые научных центров, преподаватели ВУЗов, руководители культурных центров, Домов творчества, представители тюркоязычных государств (Турция, Азербайджан, Казахстан) и 10 регионов Российской Федерации. Конференция работала в четырех секциях: «Актуальные проблемы сохранения нематериального культурного наследия», «Нематериальное культурное наследие тюркских народов: вопросы сохранения языковой среды», «Нематериальное культурное наследие тюркских народов: вопросы выявления, сохранения и исследования»; «Этническая история и традиционная культура тюркских народов». Специалисты в различных областях (диалектологи, этнографы, культурологи, правоведы, экономисты, фольклористы и др.) поделились опытом, касающимся работы с нематериальным культурным наследием на территории Российской Федерации и за рубежом. На конференции обсуждались вопросы по приоритетным направлениям и мерам государственной поддержки и сохранения нематериального культурного наследия, принципы выявления и фиксирования объектов нематериального культурного наследия тюркоязычных народов, рассматривались вопросы систематизации и изучения традиционной культуры тюркоязычных народов, а также вопросы сохранения языка как носителя нематериального культурного наследия.

17 июля в Министерстве культуры РТ прошла пресс-конференция, на которой о вопросах, поднятых в рамках конференции, рассказали заместитель министра культуры РТ Гузель Азатовна Нигматуллина, генеральный директор Государственного Российского Дома народного творчества Тамара Валентиновна Пуртова, директор Республиканского центра развития традиционной культуры Фанзиля Хакимовна Завгарова, заведующий сектором по сохранению нематериального культурного наследия Министерства культуры и туризма Республики Азербайджан Яшар Гусейнли, директор МНЦ «Хоомей» (г. Кызыл) Зоя Кыргысовна Кыргыс, ученый секретарь Казахского научно-исследовательского института культуры Министерства культуры Республики Казахстан Омарбаев Ырысбек Курбанбекович.

Данная конференция являлась идеальной площадкой, способствующей получению профессиональной информации и эффективному общению с коллегами во время работы.

---

Ученые отделения татарской филологии и межкультурной коммуникации имени Г.Тукая Института филологии и межкультурной коммуникации Казанского федерального университета приняли участие в прошедших в Турции деловых мероприятиях, направленных на развитие сотрудничества ученых в областях, представляющих взаимный интерес.

15-го октября 2014 года прошли встречи в двух университетах г.Стамбула.

Под руководством заместителя директора Института Евразии Стамбульского университета, специалиста по татарскому и башкирскому языкам отделения тюркских языков факультета литературы, профессора Исмата Бинара и ученых Университета Мармара во главе с помощником ректора университета, профессором Эролом Озваром и заведующим Института тюркологии, профессором Гульшаном Сайханом состоялась встреча студентов с заведующим отделения татарской филологии и межкультурной коммуникации, профессором А.Ш.Юсуповой, которая познакомила слушателей со структурой отделения и института, направлениями научной, педагогической и методической деятельности и предстоящими планами, рассказала о том, где и в каких сферах жизни используется татарский язык, а также о возможности обмена студентами и магистрами в целях расширения сотрудничества двух учебных заведений.

Подробные сведения Г.Р.Галиуллиной о журнале «Tatarica», выступление З.Н.Кирилловой об онлайн-школе «Ана теле» вызвали большой интерес у аудитории.

16-18 октября 2014 года во Фратском университете (г.Элязыг) прошел VII Международный симпозиум «Язык Мира – по-тюркски», в котором приняли участие 180 тюркологов со всего мира, в том числе и наши ученые. Кроме ученых из университетов Турции (гг.Стамбул, Анкара, Мармарис, Фрат, Айдын, Олы Тау, Мугла, Эгей, Османгази), также были приглашены ученые из России, Казахстана, Туркменистана, Азербайджана, Албании, Македонии, Косова, Египта, Афганистана, Китая.

На пленарном заседании выступили такие почетные тюркологи Турции, как Невзат Ялчынташ, Абдуррахман Гузель, Тунджер Гуленсой, Хамза Зульфикар, Дурсун Йылдырым, Фикрет Туркмен. В течение двух дней было прослушано 167 докладов на 29 секциях. На заседаниях, где каждый доклад был принят с большим интересом и вниманием, ученые говорили об истории, настоящем и будущем тюркских языков.

Среди делегаций, прибывших их других стран, самой многочисленной была российская – из Казани. Выступления Ф.Ю.Юсупова, Ф.Ш.Нуриевой, А.Ш.Юсуповой, Г.Р.Галиуллиной, Ф.С.Сайфулиной, Т.Ш.Гилазова, Э.Х.Кадыровой, З.Н.Кирилловой, Г.Р.Шамсиевой о периоде Золотой Орды, Казанского ханства, словарях XIX века, тюрко-татарском литературном и культурном взаимодействии в XX веке, об отдельных этнографических группах татарского народа, о сегодняшнем состоянии татарского языка вызвали у участников конференции неподдельный интерес.

На симпозиуме были намечены дальнейшие шаги совместной деятельности, подчеркнута особая роль журнала «Tatarica», который укрепит культурные и научные связи между тюркскими народами.

---

19-21 ноября 2014 года в Казани состоялся III Международный научно-практический форум «Сохранение и развитие языков и культур», проходивший на базе Института филологии и межкультурной коммуникации Казанского федерального университета.

Актуальность проведения такого мероприятия обусловлена тем, что проблема сохранения и развития языков и культур в условиях изменяющегося мира и глобализации является одной из главных для современного общества. Для ее решения необходимо проводить научно обоснованную и взвешенную языковую политику, формировать единое научно-образовательное пространство.

Только комплексные меры, систематизированный подход, а также международное и межрегиональное сотрудничество помогут сохранить языковое и культурное разнообразие мира.

Открыл форум ректор Казанского федерального университета Ильшат Рафкатович Гафуров. Он отметил, что лингвистическое направление в Казанском университете на протяжении всей его деятельности занимало одно из ведущих мест, вспомнил таких известных лингвистов, как Бодуэн де Куртенэ, Н.Крушевский, В.Богородицкий, А.Казимбек, М.Курбангалиев. «Казанский университет был и остается не только центром науки и образования, но также культуры и просвещения. Высоко оценил ректор и современную деятельность Института филологии и межкультурной коммуникации, упомянув работу Казанского международного лингвистического центра, языковых центров, проектов в рамках государственной программы «Сохранение, изучение и развитие государственных языков Республики Татарстан и других языков в Республике Татарстан на 2014 – 2020 годы», направленной на повышение авторитета русского и татарского языков и их развитие в социокультурном пространстве.

На торжественном открытии выступили директор Института филологии и межкультурной коммуникации Радиф Замалетдинов, начальник отдела международного сотрудничества и поддержки русского языка Департамента государственной политики в сфере воспитания детей и молодежи Министерства образования и науки России Саргылана Матвеевна Брызгалова, председатель Комитета Государственного Совета Республики Татарстан по культуре, науке, образованию и национальным вопросам Разиль Валиев и другие отечественные и зарубежные гости.

В работе форума приняло участие более 500 ученых, педагогических работников и руководителей учреждений образования, сотрудников федеральных, региональных и муниципальных орга-

нов управления образованием, научных и других учреждений, связанных с теоретическим и практическим изучением проблем сохранения и развития родных языков и культур, аспирантов, магистрантов и студентов высших и средних профессиональных учебных заведений Республики Татарстан, Москвы, Санкт-Петербурга, Екатеринбурга, Ростова-на-Дону, Белгорода, Нижнего Новгорода, Ставрополя, Уфы, Йошкар-Олы, Чебоксар, Саранска и других российских городов, также в форуме приняли участие ученые из стран ближнего и дальнего зарубежья: Германии, Финляндии, Турции, Латвии, Казахстана, Узбекистана и др.

В рамках форума состоялся целый ряд научных и образовательных мероприятий:

- V Международная научно-практическая конференция «Сохранение и развитие родных языков в условиях многонационального государства: проблемы и перспективы»;
- II Международная научно-практическая конференция «Искусство и художественное образование в контексте межкультурного взаимодействия»;
- Международная научно-практическая конференция «Российско-германские перекрестки: язык – образование – культура»;
- Международная научно-практическая конференция «Сохранение художественно-исторической среды современного города как духовного фактора культуры»;
- Международная научно-практическая конференция «Прикладные аспекты сопоставительной лингвистики: обучение иностранному языку с опорой на родной язык»;
- Всероссийская научно-практическая конференция «Сетевое полилингвальное обучение одаренных детей: проблемы и перспективы»;
- VII Республиканская олимпиада по татарскому языку для русскоязычных студентов.

Всего в рамках форума состоялось 2 пленарных заседания (основное и заключительное), 19 секционных заседаний, 6 круглых столов, 4 мастер-класса, в которых приняло участие более 500 человек.

III Международный научно-практический форум «Сохранение и развитие языков и культур» стал крупным научным и культурным событием и способствовал плодотворному обмену информацией и результатами научных исследований между учеными регионов Российской Федерации и стран ближнего и дальнего зарубежья. В ходе его работы были обсуждены актуальные проблемы, связанные с сохранением и развитием языков и культур, а также с изучением, распространением и обобщением передового опыта в данном направлении. В представленных на форуме научных материалах были отражены новейшие научные достижения и передовой педагогический опыт в области изучения и преподавания языков, музыки, хореографии и изобразительного искусства.

*Материалы подготовлены И.Э.Ярмакеевым, доктором педагогических наук, профессором Института филологии и межкультурной коммуникации Казанского федерального университета; Э.Х.Кадыровой, кандидатом филологических наук, доцентом Института филологии и межкультурной коммуникации Казанского федерального университета; Л.Х.Давлетшиной, кандидатом филологических наук, ведущим научным сотрудником Республиканского центра развития традиционной культуры.*